Татарстан Республикасы
Әлмәтмуниципальрайонының
Тайсуган авыл Советы

КАРАРЫ

03 март 2020 ел №79

Татарстан РеспубликасыӘлмәтмуниципаль районы Тайсуган авыл Советының 2019 елның 28 октябрендәге «Татарстан РеспубликасыӘлмәтмуниципаль районы Тайсуган авыл Советы җирлегенә керүче торакпунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турынданигезләмә хакында»гы 62 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясын, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясын һәм Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Тайсуган авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясын гамәлгә ашыру максатларында

Тайсуган авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Тайсуган авыл Советының 2019 елның 28 октябрендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Тайсуган авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә хакында»гы 62 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.2.5. пунктта «(2 нче кушымта)» сүзләрен «(үзара салым мисалында2 нче кушымта үрнәге)» сүзләренә алмаштырырга, «(3 нче кушымта)» сүзләрен «(үзара салым мисалында3 нче кушымта үрнәге)» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 2.9.2.пунктында пунктында «(5, 6 нчы кушымталар)» сүзләрен «(үзара салым мисалында5 нче, 6 нчы кушымта үрнәкләре)» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 3.1 пунктының беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Җыенга килгән гражданнар җыенны оештыручы тарафыннан теркәлә һәм торак пунктта яшәүчеләр һәм җыенда катнашырга хокуклы затлар исемлеге белән чагыштырыла»

1.4. 3.3. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.Исемлектә тегәлсезлекләр барлыгы ачыкланган очрактасайлау хокукына ия булган торак пунктта яшәүче граждан шәхесен раслый торган документлар нигезендә җыенда катнаша ала»;

1.5. 3.8. пунктында «(7 нче кушымта)» сүзләрен «(үзара салым мисалында 7 нче кушымта үрнәге)» сүзләренә алмаштырырга;

1.6. 3.17. пунктында җәя эчендәге (14 нче беркетмә) сүзләрен (14 нче кушымта) сүзләренә алмаштырырга;

1.7. 3.18 пунктта «җирлек башлыгы тарафыннан имзалана торган» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.8. 4.2. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Җыенда кабул ителгән карарлар муниципаль норматив хокукый актлар булып тора, гражданнар җыенында рәислек итүче тарафыннан имзалана һәм Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш.»

1.9.4.5. пунктында «(үзара салым мисалында 15 нче кушымта үрнәге)» сүзләрен өстәргә;

1.10. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Тайсуган авыл Советының 2019 елның 28 октябрендәге 62 номерлы карарына кушымтаны әлеге карарга 15 нче кушымта белән тулыландырырга.

1.11. Нигезләмәгәкушымталарда «Иванова Светлана Ивановна - ФАП мөдире», «Иванов Иван Ивановичны», «Петрова Полина Петровнаны» сүзләрентөшерепкалдырырга.

2. Әлеге карарны Тайсуган авылы, Сәләхетдинов урамы, 36б нчы йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Тайсуган авыл
җирлеге башлыгы урынбасары И.И.Яруллин

Татарстан РеспубликасыӘлмәт
муниципаль районы Тайсуган
авыл Советының 2020 елның
03 мартындагы 79 нчы номерлы
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Тайсуган авыл җирлегенең ______________ торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

__________ 20__ ел №........

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының35 статьясы, 20____елның "____"____________ ___ сәгать00 минутта, 20____елның "____"____________ _____ сәгать 00 минутта узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендәтүбәндәге сораулар буенча ---------------------------------------------------------------------------------------------------------------------------------- гражданнар җыены беркетмәсе төзелде

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә _____ кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны _____ кеше, бу ___% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның ______ "РИЗА" позициясе өчен тавыш бирде; гражданнар җыенында катнашучыларның______ "КАРШЫ" позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карарбирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы __________ авыл җирлегенең _________________ торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы________ авыл җирлегенең _________________ авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, даими яшәүче булган һәр балигъ булган кешедән узара салым средстволарын ______ елда______сум күләмендә кертергә.

3. Җыелган үзара салым средстволарын җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрнебашкаруга юнәлдерергә:_____________________________________________.

4.Әлеге карарны_________________________территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматларрәсми порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайты"Интернет" челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлегекарарны Татарстан Республикасымуниципаль норматив хокукыйактларырегистрынакертүеченҗибәрергә.

Гражданнарҗыенындарәислекитүче